ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 июня 2016г. № 3314

Башкарма комитетның 2013 елның 17 июлендәге 4259 номерлы карары белән расланган дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 4 өлешнең 2 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 17 июлендәге 4259 номерлы карары белән расланган дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, 2.15 пунктны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | хезмәттән файдалану урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аларда хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны да истә тотып. | |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

В.А. Гаврилов